КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 30 сентябрь г.Казань № б-2080

Урманга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан урманнарны саклау һәм торгызу мәсьәләләренә карата җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатларында, шулай ук Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын бәйрәм итү кысаларында:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

2022 елның 3 октябреннән 9 октябренә кадәр урман фонды территориясендә «Урманны саклап калыйк» дигән табигатьне саклау акциясен (алга таба – Акция) үткәрүне оештырырга;

тиешле эшләрне башлап җибәргәнгә кадәр хезмәт иминлеге буенча мәҗбүри рәвештә максатчан инструктаж үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына Акциядә катнашырга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә, Татарстан Республикасының яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территориясендә Акция оештыруны һәм анда катнашуны тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Акцияне яктыртуны, шулай ук урманга карата сакчыл мөнәсәбәт турында материаллар бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин